ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«26» август 2020 ел № 82-р

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вакантлы вазыйфалар биләүгә конкурс үткәрү турында**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турындагы нигезләмәне раслау хакында” 2013 елның 23 гыйнварындагы 12 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вакантлы вазыйфалар барлыкка килүгә бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбе муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс игълан итәргә.

2. Конкурс комиссиясе төзергә һәм аның составын расларга:

- Гыйльметдинова Римма Ринатовна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

- Сафиуллина Вәсилә Гарафетдиновна – «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

- Зудова Гөлнара Михайловна – «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең персонал белән идарә итү бүлеге башлыгы, комиссия секретаре;

- Фәтхетдинова Ләйсән Газинуровна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы, комиссия әгъзасы;

- Ершова Любовь Валерьевна – «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең тәрбия эше буенча башлыгы урынбасары, комиссия әгъзасы;

- Юсупова Аида Наилевна - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенең укыту эше буенча башлыгы урынбасары, комиссия әгъзасы;

- Маркитонов Сергей Юрьевич – Әгерҗе муниципаль районының муниципаль бюджет мәгариф учреждениеләре директорлар советы рәисе, комиссия әгъзасы (килештерү буенча);

- Мөхәмәтдинова Гөлсинә Әхмәтхановна – Татарстан Республикасы Әгерҗе районы мәгариф хезмәткәрләренең Әгерҗе территориаль профсоюз оешмасы рәисе, комиссия әгъзасы (килештерү буенча);

- Азиятуллина Раушания Наилевна – Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең 1 нче гимназиясе директоры, комиссия әгъзасы.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай урта гомуми белем бирү мәктәбенең муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры вакантлы вазыйфаларына конкурс оештыруны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И. И. Шәмсетдинов**